**Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование
«город Арск» Арского муниципального
района Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-15-25, 3-12-35**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 ел, « 20 » февраль** **№ 15**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәр башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен раслау турында**

"Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәр башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәр башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең гомуми сораулар буенча урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәр башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касимов

**Расланган**
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча шәһәре башкарма комитетының
«20» февраль 2020 ел, №_15_
карары белән

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәр башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба - мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели (алга таба-Башкарма комитет).

2. Башкарма комитетка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында башкарыла.

3. Башкарма комитетка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ тиешле чорда кергән мөрәҗәгатьләргә, шул исәптән язма рәвештә, электрон хәбәрләрне, шулай ук интернет-кабул итү, гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ел саен башкарыла.

5. Башкарма комитетка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау өчен җаваплы зат хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә, аналитик белешмә төзи.

6. Анализ үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:
- кергән, башкаларга җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрне дә кертеп, телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны;
- мөрәҗәгатьләрнең структурасы һәм тематикасы;
- шәхси кабул итү өчен җаваплы затларның шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булганда).

7. Башкарма комитетка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Башкарма комитетка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау өчен җаваплы зат ел саен аналитик белешмәне интернет-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтындагы Авыл җирлеге бүлегендә http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча "Гражданнарның мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштырылуын тәэмин итә.